**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**«Иске Котыш авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге**
**гражданнары җыены**

# КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Котыш авыл җирлеге составына керүче Красная Поляна торак пунктында

**17.10.2025 ел** **№ 2**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Котыш авыл җирлегенең Красная Поляна торак пунктында гражданнар җыены **КАРАР ИТТЕ:**

1. 2026 елда Чирмешән муниципаль районы Иске Котыш авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, Луганск халык республикасы һәм Донецк халык республикасы махсус операциясендә булган затлардан, 1 төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, 90 яшьтәге һәм өлкәнрәк гражданнардан тыш.

2. Алынган чараларны җибәрергә:

- **торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү** (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, кышкы вакытта урамнарны кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, тракторчыга исәпләнгән хезмәт хакы), Красная Поляна торак пунктында урам күрсәткечләрен һәм йорт номерларын бертөрле итеп ике дәүләт телендә (рус һәм татар телләрендә) ясау, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу.
- **торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту** (Красная Поляна торак пунктында 60 метр керә торган урам-юл челтәрен салу өчен 50-70 мм фракция вак таш сатып алу).

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Котыш авыл җирлегенең рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
ТР Чирмешән муниципаль районы
Иске Котыш авыл җирлеге башлыгы А.К.Митякин